ГЛАВА ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.02.2023 Алабуга шәһәре № 11

Алабуга муниципаль районы Башлыгы
каршындагы Инвестицион советын төзү турында

«Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында» 2011 елның 1 августындагы 50-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законнарын гамәлгә ашыру, шулай ук Алабуга муниципаль районында инвестицион климатны яхшырту максатларында,

КАРАР БИРӘМ:

1. Алабуга муниципаль районы Башлыгы каршындагы Инвестицион совет төзергә һәм аның составын расларга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башлыгы каршындагы Инвестицион совет турындагы нигезләмәне расларга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

4. Әлеге карарны контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш буенча урынбасары Р.А. Мусаевка йөкләргә.

Район башлыгы Р.М. Нуриев

Алабуга муниципаль районы
Башлыгының
“14” 02 2023 елның
11 номерлы карарына
2 нче кушымта

Алабуга муниципаль районының инвестицион климатын яхшырту буенча Иҗтимагый совет составы

| | |
|---|---|
| 1 | Алабуга муниципаль районы Башлыгы |
| 2 | Алабуга муниципаль районы Башлыгы урынбасары |
| 3 | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |

Совет әгъзалары:

| | |
|---|---|
| 4. | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| 5. | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары |
| 6. | «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты каршында төзелеш департаменты» МКУ директоры |
| 7. | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының шәһәр төзелеше һәм архитектура мәсьәләләре бүлеге башлыгы |
| 8. | Алабуга муниципаль районының Җир-мөлкәт палатасы рәисе |
| 9. | «Алабуга» МИЗ» АҖ нең эксплуатацияләү буенча урынбасары генераль директорның резидентлар белән хезмәттәшлек итү, инженер потенциалын үстерү һәм эксплуатацияләү буенча урынбасары (килешү буенча) |
| 10. | Алабуга тарихи-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы генераль директоры (килешү буенча) |
| 11. | Алабуга районында эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча) |

Алабуга муниципаль районы
Башлыгының
“14” 02 2023 елның
11 номерлы карарына
2 нче кушымта

## Алабуга муниципаль районы Башлыгы каршындагы Инвестицион советы турында нигезләмә

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Алабуга муниципаль районы Башлыгы каршындагы Инвестицион советы (алга таба - Совет) Алабуга муниципаль районы икътисадына инвестицияләр җәлеп итү мәсьәләләре буенча коллегиаль киңәшмү органы булып тора.

1.2. Үз эшчәнлегендә Совет Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары һәм әлеге нигезләмә нигезендә җитәкчелек итә.

### 2. Советның төп бурычлары һәм функцияләре

Советның төп бурычлары һәм функцияләре булып түбәндәгеләр тора:

2.1. Алабуга муниципаль районы территориясендә аларны гамәлгә ашыруның максатка ярашлы булуына һәм аларны җирле бюджет акчалары исәбеннән финанслаудан кирәкле (мөмкинлекләргә) инвестицион проектларын карау һәм анализлау;

2.2. Түбәндәге тәкъдимнәрне эшләү:

- Алабуга муниципаль районының инвестиция мәйданчыкларында потенциаль инвесторларның инвестиция проектларын урнаштыру;
- Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм инвестиция процессында катнашучы затларның үзара хезмәттәшлеген оештыру;
-административ киртәләрне, шул исәптән срокларны кыскарту һәм рөхсәт документларын бирү процедурасын гадиләштерү өлешендә киртәләрне киметү;
- Алабуга муниципаль районы үсешенең өстенлекле юнәлешләренә һәм иң өстенлекле юнәлешләрдә финанс һәм инвестиция ресурсларын координацияләү;
- Алабуга муниципаль районы икътисадына инвестицияләр күләмен арттыру механизмнарына, уңай инвестицион климат, алга киткән инвестицион инфраструктура булдыру;
- Алабуга муниципаль районы территориясендә җитештерү көчләрен рациональ урнаштыру өчен кирәкле шартлар тудыру;

- Алабуга муниципаль районы территориясендә инвестицион процессларга муниципаль ярдәм күрсәтү инвестицион активлыкны стимуллаштыру

- җирле бюджет акчалары хисабына хупланган инвестиция проектларының төп критерийларына бердәм таләпләр билгеләү;

-Алабуга муниципаль районында дәүләти-хосусый партнерлык механизмнарын кулланып, инвестицион проектларны гамәлгә ашыру.

2.3. Алабуга муниципаль районының инвестицион стратегиясе проектын карау;

2.4. Алабуга муниципаль районының инвестицион стратегиясен гамәлгә ашыру барышын һәм нәтиҗәләрен анализлау, аны үзгәртү буенча тәкъдимнәр әзерләү һәм карау;

2.5. Инвестицион проектларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен карау;

2.6. Алабуга муниципаль районының кирәкле транспорт, энергетика, социаль һәм башка инфраструктура объектларын булдыру планы проектын, шулай ук инвестиция проектлары ихтыяҗларын исәпкә алып үзгәртү регламентын булдыру.

## 3. Советның хокуклары

Совет үзенә йөкләнгән вазифаларны башкару өчен үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләргә хокуклы:

3.1 Үз утырышларында Совет компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләрне карарга һәм алар буенча карарлар кабул итәргә;

3.2 Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан билгеләнгән тәртиптә, үз компетенцияләре чикләрендә мәгълүматлар соратып алырга;

3.3 Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнары җитәкчеләрен һәм вазыйфаи затларын һәм башка органнарны һәм оешмаларны үз утырышларына чакырырга.

## 4. Совет эшчәнлеген оештыру

4.1. Совет турында нигезләмә һәм аның составы муниципаль район Башлыгы тарафыннан раслана. Совет рәисе булып - Алабуга муниципаль районы Башлыгы тора.

Совет рәисе әлеге эшчәнлек белән җитәкчелек итә, Совет утырышын алып бара, Совет утырышы планын раслый.

Совет рәисе булмаганда, аның вәкаләтләрен рәис урынбасары башкара.

Совет утырышларын әзерләү эшен оештыру секретарь тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Совет эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча секретарь Совет рәисе һәм аның урынбасары йөкләмәләрен үти.

4.2. Совет составына Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнары, инвесторлар, эшкуарларның иҗтимагый берләшмәләре вәкилләре, предприятие җитәкчеләре һәм экспертлар керә.

Инвестицион процесс субъектлары, иҗтимагый һәм башка оешмалар Совет рәисенә Совет составына кертү өчен кандидатуралар буенча үз тәкъдимнәрен җибәрергә хокуклы.

Совет үзенең эшчәнлеген аның утырышларында кабул ителгән һәм Совет рәисе тарафыннан расланган эш планнары нигезендә гамәлгә ашыра.

4.3. Совет утырышлары кирәк булган саен, әмма ике айга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Утырышларның көн тәртибен һәм аларны үткәрү тәртибен Совет рәисе билгели. Совет утырышлары «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә утырышларны Онлайн трансляцияләү юлы белән дә үткәрелергә мөмкин.

4.4. Совет утырышы, әгәр анда әгъзаларның гомуми санынннан, кимендә өчтән икесе катнашса тулы хокуклы санала.

4.5. Совет әгъзалары Совет эшенең юнәлешләренә һәм планына кагылышлы тәкъдимнәр кертәләр, Совет утырышларында кабул ителгән карарларны тормышка ашыралар, кирәкле материалларны һәм документларны өйрәнүдә һәм гомумиләштерүдә катнашалар, Советның әлеге нигезләмәсеннән һәм эш планыннан килеп чыккан башка бурычларны хәл итәләр.

4.6. Совет карарлары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм Совет рәисе һәм секретарь тарафыннан имзаланган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Карала торган мәсьәләләр буенча Совет карары утырышта катнашучыларның гомуми санынннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Карар белән килешмәгән очракта, Совет әгъзасы язма рәвештә үз фикерен утырыш беркетмәсенә теркәргә хокуклы.

Совет әгъзалары, утырышта карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча фикер алышканда, тигез хокукларга ия.

4.7. Совет эшендә кирәк булган очракта аның составына кермәгән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый һәм башка оешма вәкилләре катнаша ала.